**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге муниципаль берәмлеге гражданнар җыены карары (КАРАР)**

от «12» ноябрь 2019 г. № 2

**Мамадыш муниципаль районы**
**Усали авыл җирлеге составына керүче**
**Күк-Чишмә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында»гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 ст., Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең Күк-Чишмә авылында 2019 елның 12 ноябрендә узган үзара салым акчаларын куллану һәм кертү буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы

- Күк-Чишмә авылы торак пунктында лампалар, яктырту җиһазларын кайтарту, договор буенча хезмәт күрсәтүгә түләү;

- Күк-Чишмә авылы торак пунктында юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 9 кеше кертелгән;
халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 7 кеше;

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтижәләре түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» 7 кеше тавыш бирде;
«Юк» 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең Күк-Чишмә авылында узган халык җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең Күк-Чишмә авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Күк-Чишмә авылы торак пунктында лампалар, яктырту җиһазларын кайтарту, договор буенча хезмәт күрсәтүгә түләү;

- Күк-Чишмә авылы торак пунктында юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык ,
Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлеге
Советы рәисе ______________ А.И.Зиатдинов
(имза) (имзаның расшифровкасы)